Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең
Нагорное авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

14 ноябрь 2022 ел №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022 елның 11 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта узган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге "Сез 2023 елда елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлеге Нагорное авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Нагорное авылында су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләү?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 168 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 92 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 89 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 3 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең Нагорное авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.
2. «Сез 2023 елда елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлеге Нагорное авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Нагорное авылында су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләүгә сез ризамы?" турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.
3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Нагорное авылы, Үзәк урам, 17 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кичү авыл җирлеге башлыгы Г.П.Туманова

КИЧУЙСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ